| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы, 2019 елның 21 февралендәге ПУ-140 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-478 номерлы, 2020 елның 18 февралендәге ПУ-100 номерлы һәм 2020 елның 4 мартындагы ПУ-136 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Т. Борһановны, А.Б. Гревцовны, Г.А. Кальковны, В.А. Камалованы, В.П. Кандиловны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Гәрәев Марат Мәсгут улын – Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгын (килешү буенча);

Долгов Марат Шамил улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгын;

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

К.М. Байтимеровның – «Татарстан Республикасы фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе президенты (килешү буенча)»;

М.Р. Шаһиәхмәтовның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры, комиссия секретаре».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 12 декабрь
№ ПУ-837